РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**СОВЕТ ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

---

***Решение*** ***Карар***

**2019 елның 26 нчы сентябре** **Чистай шәһәре** **№ 47/3**

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Советының 2019 елның 23 маендагы
44/3 нче номерлы “Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районында муниципаль
хезмәт турында”гы карарына үзгәрешләр
кертү турында

“Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында”гы 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турындагы Татарстан Республикасы кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында муниципаль хезмәт турында” 2019 елның 23 маендагы 44/3 номерлы карары белән расланган нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
13 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«3. Муниципаль хезмәткә кергәндә граждан тәкъдим итә:

1) муниципаль хезмәткә керү һәм муниципаль берәмлектәге муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү турында язма гариза;

2) Россия Федерациясе гражданинының имзаланган, үз кулы белән билгеләнгән формадагы тутырылган анкета һәм фото кушымтасын өстәп;

3) паспорт һәм граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклык;

4) хезмәт кенәгәсе, хезмәт кенәгәсе (контракт) буенча беренче тапкыр төзелмәгән очракта;

5) һөнәри белеме, квалификациясе, өстәмә һөнәри белем бирү нәтиҗәләре буенча квалификация күтәрүне раслаучы документлар, гыйльми дәрәҗәсе, гыйльми исемен раслаучы документлар (булган очракта);

6) Россия Федерациясе дәүләт бүләкләре, Россия Федерациясе Президентының Мактау грамотасы белән бүләкләү турындагы карарларның

күчермәләре, Россия Федерациясе Президентының рәхмәтен игълан итү, мактаулы, хәрби һәм махсус исемнәр бирү, дәүләт премияләре бирү турындагы карарлар (булган очракта);

7) хәрби исәпкә алу документлары (хәрби бурычлылар һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле затлар өчен);

8) үзенең(хатынының, яки иренең) керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр.

9) индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу системасында, шул исәптән электрон документ формасында теркәлүне раслый торган документ;

10) Россия Федерациясе территориясендә яшәү урыны буенча физик затның салым органында исәптә торуы турында таныклык;

11) гражданнарның мәҗбүри медицина иминияте медицина полисы;

12) гражданның муниципаль хезмәткә керүгә, яки аны узуга комачаулаучы авыруның булмавын раслаучы билгеләнгән формадагы медицина бәяләмәсе.

13) “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтлар адреслары, яки сайт битләре турында мәгълүмат. Аларда муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъваитүче граждан, муниципаль хезмәткә кергәнче өч календарь елында идентификацияләргә мөмкинлек бирә торган мәгълүматлар, шулай ук һәркем өчен ачык мәгълүмат урнаштырган очракта, алдан бәян итәргә тиеш.».

3. Чистай муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә бастырырга, шулай ук Чистай муниципаль районының рәсми сайтында “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Чистай муниципаль
районы башлыгы Д.А. Иванов